КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 14

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 һәм 2023 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне межалау проектларын раслау һәм әлеге проектларга, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2022 ел, 27 июль, 722 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 һәм 2023 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне межалау проектларын раслау һәм әлеге проектларга, җәмәгатьчелек фикер алышуларын яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2022 ел, 27 июль, 722 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 февраль, 132 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2022 һәм 2023 елларда» сүзләрен «2022, 2023 һәм 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «2022 һәм 2023 елларда» сүзләрен «2022, 2023 һәм 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин